СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«05» ноябрь 2024ел.** **№143**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 25 февралендәге 56 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (14.12.2023 №115 үзгәрешләре белән)**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында "Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 56 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә (14.12.2023 N 115 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 4.6 пунктның 4.6.8 подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә:
«4.6.8. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми»;

1.2 4.8 пунктның 4.8.4. подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә:
«4.8.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2

пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы** **В.В.Сәгыйтов**